| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 25 ноябрь № 891

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014/2015 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүгә финанс чыгымнары нормативларын һәм һөнәри әзерләүне тормышка ашыруга хезмәтләр күрсәтү күләмнәре нормативларын раслау турында» 2013 ел, 26 декабрь, 1064 нче карары белән расланган 2014/2015 уку елына иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүне тормышка ашыруга һөнәр белеме бирү оешмалары күрсәтә торган хезмәтләр күләмнәре нормативларына, аларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2013 ел, 26 декабрь, 1064 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 25 ноябрь, 891 нче карары
редакциясендә)

2014/2015 уку елына иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүне тормышка ашыруга һөнәр белеме бирү оешмалары күрсәтә торган хезмәтләр күләмнәре нормативлары

| Әзерлек юнәлеше (белгечлек) коды) | Әзерлек юнәлеше (белгечлек) | Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүгә дәүләт хезмәте күләме нормативы, хөкем ителгән затлар |
|---|---|---|
| «87 нче Мамадыш һөнәр көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | | |
| 16185 | Тегү җиһазлары операторы | 40 |
| 19203 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе тракторчы-машинисты | 20 |
| 19861 | Электр җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтер | 20 |
| 16675 | Пешекче | 20». |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015/2016 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүгә норматив чыгымнарны һәм һөнәри әзерләүне тормышка ашыруга хезмәтләр күрсәтү күләмнәре нормативларын раслау турында» 2014 ел, 1 октябрь, 703 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүгә норматив чыгымнарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2014 ел, 1 октябрь, 703 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 25 ноябрь, 891 нче
карары редакциясендә)

Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче
хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүгә
норматив чыгымнар

| Әзерлек юнәлеше (белгечлек) коды | Әзерлек юнәлеше (белгечлек) | Белем алу вакыты, ай | Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүгә норматив чыгымнар, 1 елга бер хөкем ителгән затка сум | |
|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр җире | авыл җире |
| 16185 | Тегү җиһазлары операторы | 3 | 4 314 | 4 878 |
| 16675 | Пешекче | 4 | 5 260 | 5 906 |
| 19203 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе тракторчы-машинисты | 5 | 8 136 | 9 254 |
| 19861 | Электр җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтер | 5 | 7 438 | 8 407»; |

әлеге карар белән расланган ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүне тормышка ашыруга һөнәр белеме бирү оешмалары күрсәтә торган хезмәтләр күләмнәре нормативларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2014 ел, 1 октябрь, 703 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 25 ноябрь, 891 нче
карары редакциясендә)

Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче
хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүне тормышка ашыруга
һөнәр белеме бирү оешмалары күрсәтә торган хезмәтләр
күләмнәре нормативлары

| Әзерлек юнәлеше (белгечлек) коды) | Әзерлек юнәлеше (белгечлек) | Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүгә дәүләт хезмәте күләме нормативы, хөкем ителгән затлар |
|---|---|---|
| «87 нче Мамадыш һөнәр көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе | | |
| 16185 | Тегү җиһазлары операторы | 40 |
| 19203 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе тракторчы-машинисты | 20 |
| 19861 | Электр җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтер | 20 |
| 16675 | Пешекче | 20». |

3. Әлеге карардагы гамәле 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла торган 1 нче пункттан кала, бу карарның гамәле 2015 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\891.doc